*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**

(2024-2025 нче уку елы)
**11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 45**

**1. Бәет жанры турында исегезгә төшерегез. Аның үзенчәлекләрен барлап языгыз. Мисаллар китерегез. (6 балл)**

**<u>Җавап:</u>** Фаҗигалы яки көлкеле вакыйгалар, гыйбрәтле һәм гадәттән тыш хәлләр уңае белән иҗат ителгән лиро-эпик жанрдагы халык авыз иҗаты әсәре бәет дип атала. Ул шигъри формада була һәм телдән әйтелә яки көйләп башкарыла. Бәет татар фольклорына гына хас оригиналь жанр.

Мисаллар: «Сак-Сок бәете», «Сөембикә бәете», «Рус-француз сугышы бәете», «Уңмаган килен бәете».

**2. Фоторәсемгә игътибар итегез. Ул кайсы әсәр буенча ясалган? Әсәрнең исемен, авторын языгыз, әсәр геройларын атагыз. (6 балл)**



**<u>Җавап</u>**: Кәрим Тинчурин. «Сүнгән йолдызлар».

Әсәр геройлары: Сәрвәр, Исмәгыйль, Надир мәхдүм, Гөлнур карчык, Фәрхи, егетләр, кызлар.

**3. Торгынлык чоры әдәбияты кайсы чорны үз эченә ала? Дөрес җавапны билгеләгез. (2 балл)**

а) XV – XVI гасырлар

ә) XVI гасырның икенче яртысы – XVIII гасыр

б) XIX гасыр

**<u>Җавап:</u>** ә) XVI гасырның икенче яртысы – XVIII гасыр

**4. Алтын Урда чоры шагыйрен билгеләгез. (2 балл)**

а) Сәйф Сараи

ә) Габделҗәббар Кандалый

б) Муса Акъегетзадә

**<u>Җавап:</u>** а) Сәйф Сараи

**5. Әсәрләрнең авторын, жанрын языгыз. (6 балл)**

а) «И күңел...» ____________________ __________________

ә) «Яшь йөрәкләр» _____________________ _________________

б) «Мәхәббәт тәүбәсе» _____________________ __________________

**<u>Җавап:</u>**

| | | |
|---|---|---|
| а) «И күңел...» | Кол Шәриф | шигырь |
| ә) «Яшь йөрәкләр» | Галимҗан Ибраһимов | роман |
| б) «Мәхәббәт тәүбәсе» | Һади Такташ | поэма |

**6. Портретка игътибар итегез. Биредә кем сурәтләнгән? Бу әдип турында өч фактны искә төшереп языгыз. (8 балл)**



1) ____________________________

2) ____________________________

3) ____________________________

**Җавап:**

1) Гаяз Исхакый 1878 елның 22 нче февралендә Чистай өязе Яуширмә авылында мулла гаиләсенә дөньяга килә.

2) Революциядән соң эмиграциягә китә.

3) Гаяз Исхакыйның «Кәләпүшче кыз», «Бай углы», «Ике йөз елдан соң инкыйраз», «Теләнче кызы», «Кәҗүл читек», «Сөннәтче бабай», «Остазбикә», «Җан Баевич» һ.б. әсәрләре мәгълүм.

**7. Әсәрнең исемен, авторын языгыз. Әсәрне тулысы белән искә төшереп, анда бирелгән хис-кичерешләрне билгеләгез. (5 балл)**

Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк, —
Парә-парә кисмәсә гыйшык-мәхәббәт кайчысы.

Тешләренең гәүһәреннән кабызып алдым менә
Мин бу шигъре, — әйтсәңез лә, энҗедән ким кай төше?

Бу татар шагыйрьләрен мөмкиндер артка калдыру,
Алга сөрсен гашыйкый анчак мәхәббәт камчысы.

Һич хуҗалыкны кабул итмәм бөтен дөньяга мин,

Булмага мөмкин икән гыйшык, мәхәббәт ялчысы.

Әмма ләззәтле дә соң яшьрен газап, яшьрен яну! —
Бар микән, белмим, моның миннән бүтән аңлаучысы?

Барча әхраре мәхәббәт миннән уңда, зан итәм, —
Кайда Фәрһад берлә Мәҗнүн! — мин аларның таңчысы!
**<u>Җавап:</u>** Габдулла Тукай. «Мәхәббәт».
Хис-кичерешләр: мәхәббәт, ярату хисе.

**8. Мәхәббәт – ул... Әлеге фикерне дәвам итеп языгыз, әдәбияттан мисаллар китерергә дә онытмагыз. (10 балл)**